| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.08.2014 Казан ш. 1619-р

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәренең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәренә хокукларны раслаучы документлар нигезендә, «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар итте:

1. «Нижнекамскгаз» ЭПУның Түбән Кама муниципаль районы территориясендә әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы, 900 км. озынлыктагы, гомуми мәйданы 3,6 кв.км.ны тәшкил иткән газ бүлү челтәренең (газүткәргечләрнең) саклау зонасы чикләрен «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 03 июненнән 2013 елның 12 декабренә кадәр башкарылган һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 31 декабрендә килештерелгән җир өсте һәм җир асты

объектларының саклау зоналары картасындагы (планындагы) мәгълүмат буенча расларга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында газүткәргечнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итәргә:

1) газ бүлгеч челтәрнең саклау зонасы турында мәгълүматны дәүләт күчемсез милек реестрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газ бүлгеч челтәрнең саклык зонасына кергән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә чикләүләр кертелү турында мәгълүматны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны Татарстан Республикасы буенча «Росреестр федераль кадастр палатасы» филиалына юлларга, шулай ук, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары Демидов Сергей Анатольевичка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**